ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 14 апреле** **Чистай шәһәре** **№ 209**

Чистай муниципаль районы буенча
2021 елның II кварталына
торакның 1 квадрат метр
гомуми мәйданының уртача
базар бәясе турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 26 февралендәге 94/пр номерлы «2021 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» Боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елның II кварталына Чистай муниципаль районы буенча торакның 1 квадрат метрының уртача базар бәясен (сумнарда), күрсәтелгән социаль түләүләр федераль бюджет акчалары исәбеннән торак урыннары алу (төзү) өчен бирелә торган барлык категория гражданнар өчен социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен, 55 914 (илле биш мең тугыз йөз ундүрт сум) күләмендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р.Хәсәнов